ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Морквашы авылы,
422594

Тел.: (84379) 3-16-47, факс: (84379) 3-16-47.

«13» апрель № 2024 ел №6

КАРАР
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункт территориясенең бер өлешендә халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункт территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 06 ноябрендәге 7 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?:- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яр буе Морквашы авылы Луговая урамында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау) дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 13 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 34 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан җыенында катнашучылар саны 27 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 27 катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункт территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын булып узган, нәтиҗәләр - дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункт территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 06 ноябрендәге 7 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын

төзү, ремонтлау, карап тоту (Яр буе Морквашы авылы Луговая урамында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау) дигән мәсьәлә буенча караны таныргa.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И. Х. Гаязов